ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 өлешендә «1,8» саннарын «1,5» саннарына алмаштырырга;

2) 3 статьяның $2^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$2^1$. Салым ставкасы түбәндәгеләр мөлкәтенә 0,5 процент күләмендә билгеләнә:
1) йөк автотранспорты чараларын җитештерүчеләрнең;
2) инновацияле проектларны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы хөкүмәтләре карарлары нигезендә булдырылган, түләп вакытлыча хуҗа булуга һәм файдалануга яисә вакытлыча файдалануга бирү өчен каралган технопаркларның (индустриаль паркларның), инновацияле-технологик үзәкләрнең.»;

3) 5 статьяда:
а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2019 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 9, 14, 15 пунктларын, 2 өлешенең 8, 9 пунктларын, $2^1$ өлешенең 2 пунктын, 3 өлешенең 2 пунктын;»;

б) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) 2018 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 5 пунктын, 3 өлешенең 4 пунктын;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 23 июнь
№ 42-ТРЗ